**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

15.02.2021 107-п

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Карлы елгасы, Бола елгасы, Тормы елгасы, Орым елгасы, Бидәңге елгасы, Тархан елгасы, Кылна елгасы, Гөбенә елгасы, Ырым елгасы су объектларының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы 17 номерлы карары белән расланган Су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләре, Россия Федерациясе Су кодексы, «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары нигезендә һәм «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Карлы елгасының, Бола елгасының, Тормы елгасының, Орым елгасының, Бидәңге елгасының, Тархан елгасының, Кылна елгасының, Гөбенә елгасының, Ырым елгасының яр линияләре урнашкан урыннарны (су объектларының чикләрен), су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе саклык полосалары чикләрен билгеләү» 2020 елның 13 апрелендәге № 20 МЭ-2ф дәүләт контракты кысаларында башкарылган эш нәтиҗәләре буенча, су объектларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турындагы белешмәләрне дәүләт су реестрына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары һәм яр буе саклык полосалары киңлеген Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыруның махсус режимын исәпкә алып билгеләргә:

1.1. Карлы елгасы:

су саклау зонасының киңлеге – 200 м;

яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.2. Бола елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.3. Тормы елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.4. Орым елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.5. Бидәңге елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.6. Тархан елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.7. Кылна елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

1.8. Гөбенә елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 200 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге – 200 м.

1.9. Ырым елгасы:
су саклау зонасының киңлеге – 100 м;
яр буе саклык полосасының киңлеге: ярның авышлыгы 3 һәм аннан күбрәк градуска тигез булганда – 50 м, ярның авышлыгы 3 градустан кимрәк булганда – 40 м.

2. Су объектларын саклау бүлегенә (В.А.Долгов) су объектларының су саклау зоналары чикләре һәм яр буе саклык полосалары чикләре турындагы белешмәләрне дәүләт су реестрына кертү өчен Су ресурслары федераль агентлыгына һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенә (аның территориаль органнарына) җибәрергә.

3. Экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге проектларны пропа-

гандалау бүлегенә (Л.Н.Мөлекова) әлеге боерыкны татар теленә тәрҗемә итәргә.

4. Хокукый тәэминат бүлегенә (А.И.Ткачук) әлеге боерыкны теркәү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.М.Шиһаповка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков